ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2025 с.Старое Дрожжаное № 3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2020 N 1245, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 19.02.2022 N 141, 15.06.2022 N 566, 22.09.2022 N 1027, 24.05.2024 № 361, 12.09.2024 № 779 ред.) карарының гамәлдә булуын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгеле торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;
- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән хезмәт шартларының җитди үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 27 июнендәге 289 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Р.И. Мөхәммәтҗанов